# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге составына керүче Гришкино торак пунктында
2023 елга үзарасалым кертү турында

№14

19.10.2022

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлегенең Гришкино торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көек-Ерыкса авыл җирлеге Гришкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрбихәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 700 (Җиде йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Кызыл Байрак урамындагы юлларны вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю);
-урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, алмаштыру;
-юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

3.Әлеге карарны Көек-Ерыкса авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Көек-Ерыкса авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Ф.Р.Шәйхетдинов